# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

30.06.2017ел Яр Чаллы № 1875

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен эшли башлау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 30-34 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2001 елның 1 гыйнварындагы Федераль законның 14, 15 статьялары, РФ Икътисадый үсеш министрлыгының «җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2014 елның 1 сентябрендәге 540 номерлы боерыгы, Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының шәһәр төзелеше эшчәнлеге буенча ведомствоара комиссия төзү турында»2017 елның 26 июнендәге 1790 номерлы карарының 3.1 пункты нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен эшли башларга.
2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен әзерләү буенча эшләр үткәрү тәртибен һәм срокларын, кушымта нигезендәәзерләү буенча эшләр үткәрү тәртибен һәм срокларын, кушымта нигезендә расларга.
3. Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен әзерләү буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр ТР, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил проспекты, 46 йорт, 203 нче кабинет адресы буенча җибәрелә.
4. Әлеге карарны районның рәсми сайтында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Р.В. Асылгәрәев
та